Дамир Гарифуллин

Ишегалды



Дамир Гарифуллин

Ишегалды

Шигырьләр

И. КОЛМОГОРЦЕВА
рәсемнәре

Казан
Татарстан китап нәшрияты
1990

Авыл иртәсе

Тирә-як эңгер-меңгер,
Уяна инде кемдер.
Күгәрченнәр кыекта
Сөйләшә гөлдер-гөлдер...
Анда да һәм монда да
Яңгырый: «кикри-күк!»
Кыт-кыт килеп тавыклар
Җим чүпли башлый иртүк.
Нур сибеп кояш чыга,
Чаң да чоң сәгать суга.
Бозаулар уйнап-уйнап
Чабалар урам буйлап.

Тр-тр килеп трактор
Чыга авыл башына.
Пип-пип-пип! — дип кычкыртып
Узып китә машина.

Бөтен урамнар тулып
Авыл көтүе китә.
Балаларга бакчага
Барыр вакыт та җитә.

Гөрләп тора өй эче

Гөрләп тора өй эче,
Нидер эшли һәр кеше:
Әби өстәл әзерли,
Үзе:
— Хәзер, хәзер,— ди.

Әни күлмәк үтүкли:
— Кызмый бит бу
үтүк,—ди.

Ә эти әйтә көлеп:
— Утка ялга иң элек!

Үзе туфли чистарта,
Көзгедәй ялтырата...

Қарап торсаң тамаша,
Бөтен кеше кайнаша.
Бер заман кызып-кызып
(Қарап торуы кызык)
Эзләп кызыл бантикны
Бушаталар сандыкны.
Әби аны түр яктан
Табып ала серванттан.
Иркенләп өй тын ала,
Бөтенесе тын кала.
Аннан әби сүз ала,
Тагын барсы кузгала:
Әби тәмле чәй ясый,
Әни мәмәйләр ташый.
Әти дә шөгыль таба,
Ул ипигә май яга...
Шул арада, кем күрә,
Әни торып йөгерә.
Актара бөтен керне,
Арадан ала берне.
Онытып бар дөньяны,
Үтүкли башлый аны.
— Зәңгәр күлмәк кисен, ди,
Бик ярата төсен, ди.

Беләсезме ни өчен
Шулай гөрли өй эче?
Бүгеннән бит Гөлчәчәк
Бакчага йөриячәк!

Сабан туе

Ишегалды киң бит ул,
Зур мәйданга тиң бит ул.
Кара бәбкә үләнен,
Кирәк түгел келәмең!

Теләгән чакта монда
Көрәш ачарга була.
Кирәксә Сабан туен
Көн дә ясарга була.

Бүген дә бәйге бара,
Эт балаларын кара,
Әүмәкләшәләр ничек —
Өстә «дүрт күзле» көчек!

Күр, кәҗә бәтиләре
Туктаусыз сикерәләр.
Бүләк итеп аларга
Кәбестә китерәләр...

Табанына төкереп
Песи дә килеп җитә.
Капка баганасына
Тиз генә менеп китә.

Узышыпмы-узышып
Чыпчыклар чыр-чыр
җырлый.
— Көрәштә җиңдең,—
диеп
Һәркем этәчне зурлый.

Чүлмәктәге катыктан
Үрдәкләр әйбер эзли.
Ни табарлар икән дип
Аларны казлар күзли...

Кырмыскалар чиратлап
Гер күтәрә келәмдә.
Күбәләкләр җилпенеп
Тибрәнәләр үләндә.

Хәтта кара каргалар
Өй кыегына кунып
Сабан туен күзәтә
Каркылдаулардан тынып.

Мәтәлчек ата-ата
Тычканнар уйнап ята.
Менә шулай һәр көнне
Гөрләп тора ихата.

Тирә-яклар ямь-яшел,
Әйтерсең хәтфә болын.
Тып-тып биеп күрсәтә,
Шундый сөенгән колын!

...Капкалар ачык безнең
Һәммәгез дә керегез.
Рәхәтләнеп көн буе
Сабан туе күрегез!

Илнур аты

Әби җеп эрләп туйган,
Қабасын алып куйган.
Илнур аны ат иткән,
Атланып «чабып» киткән.

Әй чаба ди, әй чаба,
Әйбәт ат булган каба.
На-на! — дип куа Илнур,
Шәп ат,— дип куя Илнур.

Абыйлар һәм апалар
Аңа болай әйтәләр:
Юк, ат түгел бит, диләр,
Қаба ул,— дип көлделәр...

Бу сүзләргә Илнурның
Бер дә исе китми лә:
— Қурыкмагыз, атым ди,
Қапмый да һәм типми дә!..

Гәпләшү

Утырып баскыч төбенә,
Гәпләшә дистә малай.
Балыктан кайткач, билгеле,
Сүз тынып тормый алай.

— Унҗиде кушбаш
тоттым, — дип
Мактанып куя Хәлил.
— Мин исә ун кызылканат
Каптырдым, — дия Җәлил.

— Мин исә бозау кадәрле
Җаен каптырган идем.
Өзеп качты кармактан,
Кинәт тарттырган идем...

Шулай дип Нур шапырына
Әллә чын, әллә ялган.
Аның авызына карап
Мөхтәрәм телсез калган.

— Әй, Нур, — дип Гали
эндәшә, —
Чамаң чамага килми.
Этләй ычкындырганыңны,
Я инде, кемнәр белми!

Мин менә маймыч чүпләдем,
Күз ачып йомган саен...
Малайлар шулай гәпләшә,
Һәр сүзнең табып җаен.

Көмеш чишмә

Чылтыр-чылтыр көмеш чишмә
Яр астыннан агадыр.
Әби көн дә тәмле чәйгә
Суны шуннан аладыр.
    Көрәк тотып чишмәне мин
    Чистартып кына торам.
    Кыр-кырына ташлар түшим,
    Аннан ерганак ерам.
Әби әйтә:
— Чишмә суы
Гади түгел, серле, ди.
Ул кешегә көч бирә, ди,
Ямьли туган җирне, ди.

Тамчы

Тамчы тама кыектан,
Бар дөньясын оныткан.
Тама-тама ул шулай
Язны чакыра бугай.
Әнә бит, кара-кара:
Ул аңа юллар яра.
— Назлы яз, ди, юлга чык,
Сиңа бөтен юл ачык!

Кояшлы яңгырдан соң

Кояшлы яңгыр суына
Коенды ишегалды.
Кәгазь көймә йөздерергә
Безгә күлләвек калды.

И дулкынлана күлләвек,
Бәләкәй генә димә.
Диңгездәге кораб сыман
Тибрәнә кәгазь көймә.

Ике чеби

Бер суалчан тапканнар да,
Баш-башыннан капканнар да
Тартышалар ике чеби:
— Сиңа түгел, миңа, ди, ди,
Тартышалар уңга таба.
Тартышалар сулга таба.
Тартышалар алга-артка,
Тартышалар төрле якка...
Әй, сугышып китә болар,
Хәлдән таеп бетә болар.
Моннан исә чыпчык ота —
Суалчанны кабып йота.
Ә тегеләр авыз ачып
Калды шунда читтә басып...

Кызыл катык

Югары очтан Габделхәй
Кунактан килә кайтып.
Әбисе биргән аңарга
Бер чүлмәк кызыл катык.
Дәште дә ул үз дусларын,
Болай диде сүз катып:
— Алып чыгыгыз кашыклар,
Ашыйбыз гаҗәп катык!

Габделхәйнең бу мәзәге
Барсына кызык булды.
Авыз буялды кызылга,
Борын да кызыл булды.

Яратты бөтенесе дә:
— Әй, тәмле булды,— диләр.
Катыгы өчен әбигә
Зур рәхмәт инде, диләр.

Югалган бармак

Баш бармак, имән бармак,
Уртада — урта бармак.
Аннан соң атсыз бармак,
Соңгысы — чәнти бармак...

Тик менә безнең Самат
Бармагын санап-санап
Тәмам буталып бетә,
Берсе каядыр китә...

Саматның ул бармагын
Табып бирмәссез микән?
Кем әйтә, ул авызына
Ни кабып тора икән?

Язарга өйрәнү

Мин хәзер хәреф таныйм,
Бармакларымны саныйм.
Ә бер көнне абыйлар
Ручка алып кайттылар,
Калын дәфтәр бирделәр,
Язып тутыр, диделәр.

Ләкин ручкам бик кызык,
Сыза гел кыек сызык.
Язам дисәм тиз генә
Хәреф чыкмый төз генә.

Саннар да матур булмый,
Ә үзем эчтән уйлыйм:
«Болай булгач ручкамны
Йөдәтәчәкмен әле.
Барыбер матур язарга
Өйрәтәчәкмен әле».

Кем?

Кем түтәлдән кишер өзеп,
Шул килеш ашый башлый?
Кем ярты алма ашый да
Ртысын читкә ташлый?

Кем көн дә табын янына
Кулын юмый утыра?
Кем конфетларны өчәрләп
Авызына тутыра?

Сезнең арагызда юкмы,
Әйтегез әле чынын.
Кем икән ул, әллә нишләп
Беләсе килә шуны...

Белмәгән

— Иртән катык ашавыңны
Белеп була битеңнән.
Алсу, барчы, битең ю,— дип
Тәрбияче үтенгән.

— Белмәдегез дөресен,— дип
Тиз җавап биргән Алсу.
Катыкны мин кичә кичен
Ашадым дигән Алсу.

Уеннан кайткач

(Сильва Капутикяннан)

Айгөл уеннан кайткан,
Әбисе аңа әйткән:
— Утыр, аш ашыйк,— дигән,
Аннан чәй ясыйк, дигән...

Ә Айгөл ашамаган,
Чәйне дә ясамаган.
Нигә инде дисезме,
Әллә сез белмисезме?

Чөнки әле тавык та
Карамаган кабып та.
Сөяк көтеп көчек тә
Карап тора ишектә.
Иртүк торгач бигрәк,
Әтәчкә дә җим кирәк.
Мамык борын песи дә
Сөт көтә бу эсседә.
Ак куяннар читлектә
Кишер көтәләр бик тә...

Айгөл башта аларны
Берәм-берәм ашаткан.
Аның шулай эшләвен
Әбисе бик ошаткан.

Айгөл нык эшләп йөргән,
Көчеккә сөяк биргән,
Тавыкка тары сипкән,
Ул Әтәчкә дә җиткән.

Бер савытка салган да
Песигә сөт китергән.
Ә куяннар кишерне
Кетер-кетер кимергән...

Бөтенесен ашаткач
Әбисе белән бергә
Алар аш ашаганнар,
Аннан чәй ясаганнар,
Эчкәннәр тирли-тирли,
Бергәләп гөрли-гөрли.

Үстем

Мин хәзер бәләкәй түгел,
Мин олы булып үстем.
Бакчабызда да олылар
Группасына күчтем.

Кичә әле самавырдан
Үзем чәй ясап эчтем.
Әбиләрдә кер юышып
Бөтенләй тирләп-пештем.

Әнием белән бүген мин
Инешкә суга төштем.
Мин хәзер бәләкәй түгел,
Мин инде бик зур үстем!

Кем кайда бәллү итә

Актырнак баскыч төбендә
Әлли-бәлли, бәү итә.
Кызынып кояш нурында
Тәмле йокыга китә.

Песи тәрәзә төбендә
Әлли-бәлли, бәү итә.
Ул шулай җылы урында
Татлы йокыга китә.

Чуар тавык кетәклектә
Әлли-бәлли, бәү итә.
Бик биектә — куначада
Рәхәт йокыга китә.

Бакакак күлдә кичләрен
Әлли-бәлли, бәү итә.
Тибрәнеп дулкын өстендә
Тәмле йокыга китә.

Илнур зәңгәр коляскада
Әлли-бәлли, бәү итә.
Әбисенең экиятен
Тыңлап йокыга китә,
Тәмле йокыга китә,
Татлы йокыга китә,
Рәхәт йокыга китә...

Бакчадагы ракетада

Без ракетага тулдык,
Уйнап алырга булдык.
Очалар, диптер, Айга,
Кереп җитте Акбай да.
Камыш колак Куян да
Тын тора безнең янда.
Фил дә тапкан урынын,
Күккә чөйгән борынын.
Энем тоткан попугай,
Ул да очсын, ди, бугай...
Йөзе шат һәммәбезнең,
Кәеф шәп һәммәбезнең,
Очканнан ким түгел лә,
Күтәрелгән күңелләр...
Ракетада уйнавы
Энемә зур тантана.
Өйгә кайткач:
— Без Айга
Очтык диеп мактана.

Усал туп

Тора салып гел юкка
Айрат типкән күн тупка.
Үзе аннан шаккаткан:
Туп тәрәзәне ваткан.

Ишек буе көзгене
Чәлпәрәмә китергән.
Өстәлдәге гөлләрне
Гел аударып бетергән.

Ә аннан соң тып-тып-тып
Сервантны эзләп тапкан.
Уйлап-нитеп тормаган,
Чынаякларны ваткан.

Нигә ваткан дисезме?
Белмисезме шуны да?
Айрат усалланганда
Усаллана тубы да.

Илнур һәммәсен таный

Төрле кошлар, җәнлекләр
Яшиләр ди урманда!
Илнур иртүк торган да
Шул урманга барган да
Кереп шактый эченә
Кычкырган бар көченә:
— Җәнлекләр, кошлар! — дигән.—
Чыгыгыз, дуслар! — дигән.

Әйдәгез безгә, дигән,
Сүзем шул сезгә, дигән,
Мин сезне кунак итәм,
Кич белән өйдә көтәм!

Тегеләр күренмичә
Һәм бер дә иренмичә —
Барсы да бермә-бермә
Илнурга сорау биргән:

— Мин барсам,— дигән
Куян,—
Танырсың микән? — дигән.—
Кунак итеп син каршы
Алырсың микән? — дигән.

Ә Илнур болай әйткән:
— Сине ерак-еракτан
Колагыңнан танырмын;
Каршы чыгып алырмын.

Син бик матур чабасың,
Шәп сикерә аласың.
Танымас димә мине,
Кил яме, көтәм сине!

— Мин дә бармакчы булам,
Танысаң,— дигән Болан.—
Әйт, мине танырсыңмы?
Әйт, каршы алырсыңмы?

Илнур аңарга әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Мөгезеңнән танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

— Соң мин дә болай булгач
Барам,— дигән Сандугач.—
Тик мине танырсыңмы
Һәм каршы алырсыңмы?

Илнур болай дип әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Сайравыңнан танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Чут-чут, чут-чут килүең,
Моң тарата белүең
Күптәннән таныш миңа,
Кил! — Әйтү шушы сиңа!

— Мин,— дигән Тавис кошы,—
Барырмын беткәч эшем.
Тик мине танырсыңмы
Һәм каршы алырсыңмы?

Илнур аңа да әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Кауреңнан танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Керпе әйткән шул чакта:
— Мин дә калмыйча артка
Барырмын таныр булсаң
Һәм каршы алыр булсаң.

Ә Илнур аңа әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Энә-туннан танырмын,
Чыгып каршы алырмын.

— Мин барсам,— дигән
Төлке,—
Син танымассың, дигән.
Кунак итеп өеңә
Каршы алмассың, дигән.

Илнур аңарга әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Койрыгыңнан танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Көлтә-көлтә койрыгың
Себермәсен эзеңне!
Мин болай да барыбер
Таный беләм үзеңне!

Аю да әйтеп куйган:
— Мин дә барырмын,
туган.
Ләкин танырсың микән,
Каршы алырсың микән?

Ә Илнур аңа әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Йөрешеңнән танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Дөя дә үз сүзендә
Әйткән:
— Барыр идем дә
Мине танырсың микән,
Каршы алырсың микән?

Илнур аңарга әйткән:
— Сине ерак-ерактан,
Чыгу белән йортыңнан,
Тау-тау төсле сыртыңнан —
Өркәчеңнән танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Тынып тормады Фил дә:
— Барырмын, диде, мин дә.
Ләкин танырсың микән,
Каршы алырсың микән?

Ә Илнур аңа әйткән:
— Сине ерак-ерактан
Борыныңнан танырмын,
Каршы чыгып алырмын.

Җилфер-җилфер колагың,
Тәпән-тәпән аягың.
Таныш миңа һәммәсе —
Сүз бер булсын: киләсең!

Шулай дип киңәшкәннәр,
Шулай дип килешкәннәр.
Серләрне бүлешкәннәр,
Бергәләп көлешкәннәр.

Кунакларны кич белән
Илнур каршы алган ди.
Бөтенесе шул чакта
Тәмам хәйран калган ди.

Кунакларның һәрберсен
Ничек таный, дигәннәр.
Исемнәрен дә белә —
Һич бутамый, дигәннәр.

Ник бутасын — бутамый,
Берсен ялгыш атамый.
Чөнки барлык кошларны,
Киек җәнлек-дусларны
Илнур таный белә ул,
Бөтен сере менә шул!

Ишегалдында

Каз, үрдәк һәм тавыкларга
Җим салынган савытларга.
Бозау йөри мөгри-мөгри,
Тамак кырып юри-юри.
Күзен бераз ачып кына,
Песи ята качып кына.
Сарбай аны каян күрә —
Бәйдә килеш һаман өрә...
Чыпчык кына авыз ерып
Көлеп йөри чырык-чырык...

Август

Җиләкләр беткән чаклар,
Шомыртлар кипкән чаклар.
Бәрәңге үскән чаклар,
Алмалар пешкән чаклар.

Миләшләргә бүрек-бүрек
Кызыл ут капкан чаклар.
Арыш башакларын уып
Куаныч тапкан чаклар.

Төрле-төрле эшләпәле
Гөмбәләр үскән чаклар.
Бөтен авыл белән бергә
Уракка төшкән чаклар.

Өем-өем помидорлар
Кызарып яткан чаклар.
Җир җимертеп болыннарда
Колыннар чапкан чаклар.

Белдеңме инде син, дус,
Менә нинди ул август!

Табышмак әйтешү

Көн дә бергә җыелып,—
Буламыни тыелып,—
Берәүнең башлау җитә,
Табышмак әйтү китә:
— Боз дисәң, боз түгел ул,
Тоз дисәң, тоз түгел ул.
Кар дисәң, кар түгел ул,
Бал дисәң, бал түгел ул.
Әбиләр дә ярата,
Нәниләр дә ярата,
Кашык белән аз-аз кабып
Ашыйлар бөтен җирдә.
Нәрсә ул? — ди Гөлгенә
Җавап инде бер генә:
«Морожный!» — диләр өзеп.
Айнур да тормый түзеп:
— Көн болытлаган чакта,
Әллә кайда еракта
Хәтәр көтүче йөри,

Озын чыбыркы сөйри...
Әй шартлата шарт та шорт,
Чыбыркысы ялт та йолт.
Күк йөзен йөзгә телә,
Нәрсә ул, кемнәр белә?
— Мин беләм! — ди бер малай,
Күтәреп тормый алай.
Бөтенесен дә узып:
— Яшен ул! — диде сузып.
Табышмак әйтә Чулпан.
Башларын вата Чулпан:
— Бер озын аркан ята,
Үз-үзен уктай ата.
Карап торсаң бик кызык,
Кайчакта кызып-кызып
Әллә кая юнәлә,
Ә кайчакта төйнәлә...
Үзе кайчак сызгыра,
Үзе кайчак ыжгыра,
Ә кайчакта шым гына
Качып китә тын гына.
Айгөл Наилә белән:
— Елан ул,— диләр,— елан!

Мин дә табышмак әйтим
Диеп кушыла Хәким:
— Кара җәймә өстенә

Утлы борчак түгелгән.
Моңа инде җавапны
Табу кыен түгел лә...
— Йолдызлар ул, йолдызлар! —
Диеп кабатлый кызлар.

— Болытлардан юл ала,
Җиргә кереп югала...
— Яңгыр ул! — дип шунда ук
Әйтеп куя бер бала.

Көн дә шулай җыелып,—
Буламыни тыелып,—
Берәүнең башлау җитә,
Табышмак әйтү китә.

Бозлавыкта

Ишегалды бозлавык,
Йөгереп йөри ун тавык.
Кикринур карап тора,
Бик хәтәр тамак кыра.

Аннан әйтә болай дип:
— Сездән чыпчык көлә бит,
Әйбәт ич, ди, бозыгыз,
Йөгермәгез, шуыгыз!

Беләбез, дип, беләбез
Кыт-кыт көлә тавыклар.
Бик тә шуар идек лә,
Юк бит тимераяклар!

Мөрәҗәгать язу

Берәү баскычка утырган,
Берәү үләнгә яткан,
Берәү читтә басып тора,
Берәү ак кәгазь тапкан...
— Яз, Фәрит! Үзбәк абыйлар,
Әрмән абыйлар, диген,
Бездә сезнең талашларны
Гаеп саныйлар, диген.
Төрек тә ана баласы,
Яшәсен тыныч, диген.
Азәрбайҗан да, әрмән дә
Алсын тын сулыш, диген.
— Фәрит, яз! Сезнең ызгышу
Безгә дә оят, диген.
Бездә араны бозышу
Бөтенләйгә ят, диген.
— Яз, Фәрит! Грузин, абхазлар,
Тату торыгыз, диген.

Дөньяда безнең шикелле
Тормыш корыгыз, диген.
Бездә дә төрле милләттән
Халыклар яши, диген.
Кирәк булса бер табактан
Җыелып ашый диген.
Болай дип яз: — Алар көн дә
Бергә күңел ачалар.
Чөнки рус, башкорт һәм татар
Кодалар, кодачалар...
Алар бергә яши, диген,
Бер-берсеннән бизмиләр.
Хәзер диген чуваш, удмурт
Җиңгиләр һәм җизниләр.
Хат яза бала-чагалар —
Гөр килә ишегалды.
...Чү кинәттән нәрсәгәдер
Барсы да тынып калды.
— Язуын язабыз да бит
Хатны кая җибәрик,
Шулай диеп әйтеп куйды
Каләм иясе Фәрит.
Алар озак уйлаштылар,
Төрлечә баш ваттылар.
Уйлый торгач үзләренчә
Бер әмәлен таптылар:
«Мәскәүгә. Туган илебез
Халкына Мөрәҗәгать».
Адресы шулай язылгач,
Һәркем булды канәгать.

ЭЧТӘЛЕК

Авыл иртәсе . . . 2
Гөрләп тора өй эче . 3
Сабан туе 5
Илнур аты 7
Гәпләшү 8
Көмеш чишмә . . . 9
Тамчы 9
Кояшлы яңгырдан соң 10
Ике чеби 11
Кызыл катык . . . 11
Югалган бармак . 12
Язарга өйрәнү . . 13
Кем? 13
Белмәгән 14
Уеннан кайткач . . 15
Үстем 16
Кем кайда бәллү итә 17
Бакчадагы ракетада 18
Усал туп 19
Илнур һәммәсен таный 19
Ишегалдында . . 25
Август 25
Табышмак әйтешү . 26
Бозлавыкта . . . 28
Мөрәҗәгать язу . . 29

ББК 84 (2Р-Тат)-5
Г 22

МӘКТӘПКӘЧӘ ЯШЬТӘГЕ БАЛАЛАРГА

Издание для детей и юношества

Гарифуллин Дамир Хайруллович

ПОДВОРЬЕ

Стихи

(на татарском языке)

Редакторы *Т. Нурмөхәммәтова*
Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*
Техник редакторы *Ф. Абдрахманова*
Корректоры *Ф. Гыйниятуллина*

ИБ № 5708

Җыярга тапшырылды 28.02.90. Басарга кул куелды 15.10.90. Форматы $60\times90^{1}/_{16}$. Типогр. кәгазе № 1. Литературная гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 5,0. Нәшер-хисап табагы 2,27. Тиражы 10 000 экз. Заказ Л-101. Бәясе 15 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан ССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.

$Г\frac{4803560202-237}{М\ 132(03)-90}$ — 187—90

ISBN 5—298—00487—3

© Дамир Гарифуллин, 1990
© И. Колмогорцева, рәссам, 1990



15 тиен.